**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ЛАИШЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610
Тел: 8-(84378) -2-52-28
Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышев урамы, 23 нче йорт Лаеш ш.
422610
Тел: 8-(84378) -2-52-28
Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.

---

2020 елның 26 июне 1173 номер

**КАРАР**

**«Имәнлек» коттедж поселогы территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектына үзгәрешләр кертүгә әзерлек турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 43, 45, 46 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә, территорияне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, планлаштыру структурасы элементларын (кварталлар, микрорайоннар, башка элементлар) бүлеп бирү, капиталь төзелеш объектлары урнашкан җир кишәрлекләре чикләрен, линия объектларын төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлегендә урнашкан «Имәнлек» КП территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектына үзгәрешләр кертүне әзерләргә.
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлегендә урнашкан «Имәнлек» коттедж поселогы территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектына үзгәрешләр кертү срогын 2020 ел дәвамында билгеләргә.
3. Территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектына үзгәрешләр кертү документларын әзерләү һәм карап тоту тәртибе, сроклары турындагы тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының башкарма комитеты тарафыннан түбәндәге адрес буенча эш көннәрендә кабул ителә: Татарстан Республикасы, Лаеш шәһәре, Чернышевский ур., 23 й..
4. Әлеге карарны «Кама ягы» («Камская новь») район газетасында, махсус мәгълүмат стендларында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштырырга(халыкка җиткерергә).
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **И.Ф. Зарипов**